ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 586-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 586-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2568-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8–9; 2016, № 1–2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $1^1$ статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата салым базасы аларның билгеләнгән тәртиптә расланган кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә.»;

2) 2 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата салым ставкасы 2 процент күләмендә билгеләнә.»;

3) 3 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлектәге $3^2$ өлешне өстәргә:

«$3^2$. Салым әлеге Законның $1^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән күчемсез милек объектларына карата исәпләнгән салым суммасының 60 проценты күләмендә түләнә, халык саны 145 мең кешедән артык булган торак пунктлар

территорияләрендә урнашкан гомуми мәйданы 2000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннардан тыш.»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салым түләүчеләргә әлеге статьяның 1 – $3^1$ өлешләрендә билгеләнгән салым ташламалары салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата бирелми.»;

4) 5 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 13 пунктны өстәргә:

«13) 2028 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясының $3^2$ өлеше.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
# АҢЛАТМА

Россия Федерациясе Салым кодексының 378[2] статьясына ярашлы рәвештә административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата салым базасы мөлкәтнең кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында халык саны 145 меңнән артык булган торак пунктлар территориясендә (Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләре) урнашкан, мәйданы 2 000 кв. метрдан артык булган сәүдә объектларына кадастр бәясенә тәңгәл салым салына.

Закон проекты белән, аны гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы урыннар белән тулыландырып, аңа карата салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез милек исемлеген киңәйтергә һәм 2025-2027 елларга исәпләнгән салым суммасының 60 проценты күләмендә салым түләүне билгеләү тәкъдим ителә.

Идел буе федераль округы субъектларында кадастр бәясенә тәңгәл салым салу сәүдә объектларыннан тыш административ-эшлекле үзәкләргә дә кагыла. Шул ук вакытта сигез субъектта мәйдан буенча чикләү билгеләнгән, калганнарында чикләүләр юк. Шулай ук 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 елларның план чорына Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләрендә барлык объектларга карата кадастр бәясеннән чыгып, оешмаларның күчемсез милегенә салым салуга күчү каралган.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә**
**үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга,**
**үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы**
**законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

## ИСЕМЛЕГЕ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар төшеп калуга китерми.